КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 27 гыйнвар г.Казань № 45

2017 елның IV кварталы өчен Татарстан Республикасында халыкның җан башына һәм халыкның төп социаль-демографик төркемнәре буенча яшәү минимумы күләмен раслау турында

«Россия Федерациясендә яшәү минимумы турында» 1997 ел, 24 октябрь, ФЗ-134 нче Федераль закон, «Татарстан Республикасында халыкның җан башына һәм халыкның төп социаль-демографик төркемнәре буенча яшәү минимумы күләмен билгеләү тәртибе турында» 2005 ел, 20 июль, ТРЗ-92 нче һәм «Татарстан Республикасында куллану кәрзине турында» 2013 ел, 13 июль, ТРЗ-62 нче Татарстан Республикасы законнары нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

2017 елның IV кварталы өчен Татарстан Республикасында яшәү минимумы күләмен халыкның җан башына исәпләгәндә – 8 334 сум, эшкә яраклы халыкка – 8 877 сум, пенсионерларга – 6 822 сум, балаларга 8 326 сум итеп расларга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин